РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.06.2026 №129-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгының 2013 елның 14 маендагы 55-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы гражданнарының аерым категорияләренә - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы халкына түләүсез юридик ярдәм күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

2026 елның 23 мартындагы 64-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» Федераль законның 20 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгының «Саба муниципаль районы гражданнарының аерым категорияләренә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2013 елнын 14 маендагы 55-п номерлы карары белен расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы халкына - гражданнарның аерым категорияләренә - түләүсез юридик ярдәм курсәту тәртибенә тубәндәге узгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта түбәндәге эчтәлекле 2.16 һәм 2.17 пунктчалар өстәргә:

«2.16. Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы ата-аналар, өлкән баласы унсигез яшькә җиткәнче яисә егерме өч яшькә җиткәнче, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алу шарты белән;

2.17. социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә, аларны мәҗбүри күченүчеләр, качаклар дип тануга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны алуга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны алуга яисә Россия Федерациясе гражданлыгына кабул итүгә бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, аларны мәҗбүри күченүчеләр, качаклар дип тану турында үтенеч белән мөрәҗәгать итүче затлар.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru.рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Миңнеханов